**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
**IV чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**IV созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

13.12.2018 ел ___________

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы балигъ булмаган балалар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия төзү турында

Балигъ булмаган балаларның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау һәм аларның хокукларын яклау мәсьәләләрен, «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон белән йөкләнгән бурычларны уңышлы үтәүне тәэмин итүдә органнар һәм учреждениеләр эшчәнлеген координацияләүгә бәйле проблемаларны нәтиҗәле хәл итү максатларында, «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1.Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты каршында балигъ булмаган балалар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия төзергә һәм аның составын кушымта нигезендә расларга.

2.Актаныш муниципаль районы Советының «Балигъ булмаган балалар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия төзү турында» 2011елның 22 декабрендәге 13-02 номерлы карарын (Актаныш муниципаль районы Советының 28.03.2013 ел. № 27-08, 03.12.2013 ел. № 34-04, 04.08.2016 ел. № 08-09, 23.11.2016 ел. № 1105, 14.11.2018 ел. № 32-06 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) үз көчләрен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында http://aktanysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет рәисе Э.Н.Фәттахов

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты каршында
балигъ булмаган балалар белән эшләү һәм аларның хокукларын
яклау комиссиясе составы

Нурлыева Л.Ф. Актаныш муниципаль районы балигъ булмаган балалар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе рәисе, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары;

Шәфикова Н.Р. комиссия рәисе урынбасары, «Актаныш муниципаль районы мәгариф идарәсе» дәүләт казна учреждениесе башлыгы (килешү буенча).

Хаҗиева З. М. - комиссиянең җаваплы секретаре.

Комиссия әгъзалары:

Бариева Л.Ф. ТР Актаныш муниципаль районының социаль яклау бүлеге башлыгы;
_

Закирҗанова Р.И._ «Игелек узеге» халыкка хезмәт күрсәтү, дәүләт автоном учреждениесе директоры;

Мансуров А.М. - Социаль культура һәм агарту эшләре бүлеге башлыгы;

Фазлиева Л. М. _ Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы.

Иманаев А. И. _ Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җитәкчесе.

Салихов Н.М. _ «Актаныш муниципаль районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе директоры (килешү буенча).

Минхуҗин Л.С. _ гомуми практика табибы, - «Актаныш район үзәк хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең табиб-наркологы (килешү буенча).

Сәлахова Н.З. _

Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлегенең полиция участок уполномоченныйлары бүлекчәсе һәм балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәсе балигъ булмаганнар эшләре буенча төркемнең өлкән инспекторы, полиция өлкән лейтенанты (килешү буенча).

_Гыймадиева Ф.Ф. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Ихлас» психологик-педагогик медицина-социаль хезмәте җитәкчесе (килешү буенча).

Сәлимов Д.З. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы_

Имамразыева Р.Ф.- «Районара җинаять-үтәтү инспекциясе» Федераль бюджет учреждениесенең 4 нче җинаять-башкарма инспекциясе өлкән инспекторы, Россия җәза үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан

Республикасы буенча Баш идарәсе, эчке хезмәт майоры (килешү буенча).

Гарифуллина И.Т. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Актаныш районы «Игелек үзәге» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм бүлекчәсе мөдире (килешү буенча).

Ендальцева С.Г. «Актаныш район үзәк хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең район педиатры (килешү буенча).